**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 27 апрелендәге 1435 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 16 мартындагы 793 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесы дублерыннан Идел буе урамына кадәр тимер юл аша юлүткәргеч белән автомобиль юлы төзү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Төзелеш кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 933 номерлы «Раслау турындагы карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне ызанлау проектлары, территорияне планлаштыруның мондый проектларына һәм территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертү җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырмыйча раслана торган очракларны билгеләү турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 16 мартындагы 793 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Казан

шәһәренең Киров районында Горький шоссесы дублерыннан Идел буе урамына кадәр тимер юл аша юлүткәргеч белән автомобиль юлы төзү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына, территорияне ызанлау проектының аерым өлешләрен әлеге карар кушымтасы нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 27 апрелендәге
1435 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 16 мартындагы 793 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесы дублерыннан Идел буе урамына кадәр тимер юл аша юлүткәргеч белән автомобиль юлы төзү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләр**

V «Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше» бүлегендә:

1. Дүртенче абзацта җир кишәрлегенең «16:50:280564:417» кадастр номерын җир кишәрлегенең «16:50:280564:423» кадастр номерына алмаштырырга.

2. 1 таблицада, «2 нче этап» бүлегендә, 4 юлда, «Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры» графасында җир кишәрлегенең «16:50:280564:417» кадастр номерын җир кишәрлегенең «16:50:280564:423» кадастр номерына алмаштырырга.

3. 2 таблицада, 32 юлда, «Ясала торган җир кишәрлегенең шартлы номеры, гамәлдәге җир кишәрлегенең кадастр номеры» графасында җир кишәрлегенең «16:50:280564:417» кадастр номерын җир кишәрлегенең «16:50:280564:423» кадастр номерына алмаштырырга, «Гамәлдәге җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м» графасында «402» санын «601» санына алмаштырырга.

4. 2 таблицадан соң түбәндәге эчтәлектәге искәрмә өстәргә:

«Искәрмә. Җир кишәрлекләре мәйданнары ачыклау кысаларында үзгәрергә мөмкин».

5. 3 таблицада, «Сервитут/ачык сервитут белән урнаштырылган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары» графасында «16:50:280564:417» кадастр номерын «16:50:280564:423» кадастр номерына алмаштырырга, «Беренчел җир кишәрлеге мәйданы» графасында «402» санын «601» санына алмаштырырга.

____________